| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 февраль 2014 ел Казан шәһәре **Карар №** 10-4/кс

***ЯАЖ «Стройтех» филиалы «Чистай-Суканалы» өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызу тарифларын билгеләү турында***

“Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында” 7 декабрь, 2011 ел, № 416-ФЗ Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 13 май, 2013 ел, №406 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә гамәлдәге тарфиларның максималь мөмкин булган үзгәртү чик индексларын, 2014 елда уртача Россия Федерациясе буенча билгеләү турында” 21 октябрь, 2013 ел, №192-э/3 Тарифлар буенча Федераль хезмәтенең боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган ЯАЖ “Стройтех” филиалы “Чистай-Суканалы” өчен әлеге карарның кушымтасына таянып, календарь бүленеше нигезендә, эчәргә яраклы һәм ташландык суларны агызу тарифларын билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 1 аперленнән 2014 елның 31 декабренә кадәр үз көчендә була.

3. ЯАЖ “Стройтех” филиалы “Чистай-Суканалы”на Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17 гыйнвар, 2013 ел, № 6 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе вазыйфаларын
башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
кушымта
14 февраль 2014 ел № 10-4/кс

# Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган ЯАҖ «Стройтех» филиалы «Чистай-Суканалы» өчен, календарь бүленеше нигезендә, эчәргә яраклы һәм ташландык суларны агызу тарифы

| № п/п | Муниципаль берәмлек, оешма, салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган оешмалар исеме | Салкын суга тариф (берставкалы), сум/куб.м | | Ташландык суны агызу (берставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01 апрель 2014 ел - 30 июнь 2014 ел | 01 июль 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | 01 апрель 2014 ел - 30 июнь 2014 ел | 01 июль 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел |
| | Чистай муниципаль районы | | | | |
| 1 | ЯАҖ «Стройтех» филиалы «Чистай-Суканалы» | | | | |
| | Торак секторы кулланучылары (тарифларда ӨБС исәпкә алынган) | 26,79 | 28,62 | 31,10 | 31,10 |
| | Башка кулланучылар (ӨБС исәпкә алынмаган) | 22,70 | 24,25 | 26,36 | 26,36 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге